**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
СЮНДЮКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СӨЕНДЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

422396 с.Сюндюково, ул.Такташа, 15

422396 Сөендек авылы,Такташурамы, 15

тел. (84373) 5-07-27, факс 5-07-27, e-mail: ssundukovo@mail.ru
ОГРН 1021606557136, ИНН/КПП 1638001663/163801001

**18 .06. 2024** **№ 36-1**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**"Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында" Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Сөендек авыл җирлеге Советының 2023 елның 16 июнендәге 27-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45 ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Сөендек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Сөендек авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Сөендек авыл җирлеге Советының "җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында"гы 2023 елның16 июнендәге 27-1 номерлы карарының 1 пунктын, түбәндәге эчтәлектәге 8 нче пункт белән тулыландырырга:

8) физик затларда Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Сөендек авыл җирлеге башлыгы Измайлов Хафиз Әхмәт улына йөкләргә.

**Җитәкче** **Х.А.Измайлов**